КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март

г.Казань

№ 307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021 ел, 11 февраль, 70 нче; 2021 ел, 24 май, 366 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1026 нчы; 2022 ел, 22 гыйнвар, 39 нчы; 2022 ел, 11 июль, 665 нче; 2022 ел, 12 декабрь,

1315 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) хосусый медицина оешмасы учреждение чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

9 пунктта:

«а» пунктчасының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хосусый медицина оешмасының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган документ;»;

«б» пунктчасында «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы» сүзләрен «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин